ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 мая 2020 г. № 2313

Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру тәртибе хакында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, гражданнарның һәм оешмаларның Башкарма комитет эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарларын, Башкарма комитетның районнар хакимиятләре Башлыкларын, Башкарма комитетның структур бүлекчәләре идарәләренең (бүлекләренең) башлыкларын, күрсәтелгән структур бүлекчәләр статусын билгеләүче хокукый актлар нигезендә, Башкарма комитет эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру өчен җаваплы итеп билгеләргә.

3. Башкарма комитетның «Башкарма комитет эшчәнлеге хакында мәгълүмат алуны оештыру тәртибе турында» 2010 елның 22 июлендәге 4833 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 19 маендагы
2313 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитет эшчәнлеге турында
мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру
тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру тәртибе (алга таба – Тәртип) «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 8-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә эшләнгән һәм Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү ысулларын, Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру тәртибен билгели.

2. Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итүнең төп принциплары, шулай ук Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүмат эзләүне гамәлгә ашыручы гражданнарның (физик затларның), оешмаларның (юридик затларның), иҗтимагый берләшмәләрнең хокуклары 8-ФЗ номерлы Федераль законның 4 һәм 8 статьяларында тиешенчә билгеләнгән.

Башкарма комитет эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге 8-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясында каралган очракларда чикләнә.

3. Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүмат телдән һәм язма рәвештә, шул исәптән электрон документ рәвешендә бирелә.

Башкарма комитет эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге түбәндәгечә тәэмин ителә:

1) мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару (халыкка җиткерү);

2) мәгълүматны «Интернет» челтәренә урнаштыру;

3) мәгълүматны Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән бүлмәләрдә һәм әлеге максат өчен билгеләнгән башка урыннарда урнаштыру һәм аның белән таныштыру;

4) мәгълүматтан файдаланучыларны китапханә һәм архив фондлары аша таныштыру;

5) гражданнарның (физик затларның) Башкарма комитетның коллегиаль органнары утырышларында катнашуы;

6) мәгълүматтан файдаланучыларның запросы буенча аларга мәгълүмат бирү;

7) законнарда һәм башка норматив хокукый актларда, муниципаль хокукый актларда күздә тотылган башка ысуллар ярдәмендә.

5. Башкарма комитетның Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану хокукын бозуда гаепле вазыйфаи затлары 8-ФЗ номерлы

Федераль законның 25 статьясында каралганча җаваплы булалар. Вазыйфаи затларның хокуклары һәм бурычлары аларның вазыйфаи инструкцияләрендә беркетелә.

6. Вазыйфаи затлар 8-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясында билгеләнгән очракларда, Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүматны бирмәскә хокуклы.

7. Мәгълүматтан файдаланучыларның Башкарма комитет эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану хокукын бозучы вазыйфаи затларның карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәвенә) карата, алар тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

## 2 бүлек. Мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру

8. Башкарма комитет эшчәнлеге турындагы мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару Россия Федерациясенең массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

9. Муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Шәһәр Советының «Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары, Башкарма комитетның «Шәһәр Башкарма комитеты Җитәкчесенең норматив хокукый актларын Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкына бирү һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2006 елның 17 февралендәге 35 номерлы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

10. Массакүләм мәгълүмат чараларына бирелә торган мәгълүмат «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында тарату чикләнгән хезмәт мәгълүматы белән эш итү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 16 ноябрендәге М 509 номерлы карары нигезендә дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларны, шулай ук тарату чикләнгән хезмәт мәгълүматын үз эченә алырга тиеш түгел.

## 3 бүлек. Мәгълүматны «Интернет» челтәренә урнаштыру

11. Башкарма комитет эшчәнлеге турындагы мәгълүмат «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында www.nabchelny.ru урнаштырыла.

12. Башкарма комитет эшчәнлеге турында «Интернет» челтәренә урнаштырыла торган мәгълүмат исемлеге, Башкарма комитетның рәсми сайты белән идарә итү һәм аны мәгълүмат белән тулыландыру Башкарма комитет боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4 бүлек. Мәгълүматны Башкарма комитет тарафыннан биләнгән бүлмәләрдә һәм әлеге максат өчен билгеләнгән башка урыннарда урнаштыру

13. Башкарма комитет эшчәнлеге турында агымдагы мәгълүмат белән танышу өчен, Башкарма комитет бинасында мәгълүмат стендлары һәм мәгълүмат терминаллары урнаштырылырга мөмкин.

14. Әлеге тәртипнең 13 пункты нигезендә, урнаштырыла торган мәгълүмат

түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) гражданнарны (физик затларны), шул исәптән оешма (юридик затлар), иҗтимагый берләшмә вәкилләрен кабул итү тәртибен кертеп, Башкарма комитетның эш тәртибе;

2) Башкарма комитеттан мәгълүмат алу шартлары һәм тәртибе;

3) Башкарма комитет хезмәткәрләренең кабинет номерларын күрсәтеп, телефоннар исемлеге;

4) муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең телефоннар исемлеге;

5) Башкарма комитет структур бүлекчәләренең белешмәләр хезмәте телефоннары;

6) Башкарма комитет Җитәкчесенең, аның урынбасарларының, Башкарма комитетның структур бүлекчәләре җитәкчеләренең шәхси сораулар буенча гражданнарны кабул итү графигы.

15. Агымдагы мәгълүматны мәгълүмат стендларына Башкарма комитетның тармак структур бүлекчәләре урнаштыра.

16. Әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә урнаштырыла торган мәгълүмат түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) гражданнарны (физик затларны), шул исәптән оешма (юридик затлар), иҗтимагый берләшмә вәкилләрен кабул итү тәртибен кертеп, күрсәтелгән структур бүлекчәләренең эш тәртибе;

2) мәгълүмат алу шартлары һәм тәртибе;

3) Башкарма комитетның структур бүлекчәсе хезмәткәрләренең кабинет номерларын күрсәтеп, телефоннар исемлеге;

4) Башкарма комитет структур бүлекчәләренең белешмәләр хезмәте телефоннары;

5) «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайты адресы, структур бүлекчәләрнең сайты адресы (булган очракта);

6) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә башка мәгълүмат.

17. Башкарма комитетның күрсәтелгән структур бүлекчәләрендә файдаланучыларга «Интернет» челтәрендә урнаштырыла торган Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итә торган мәгълүмат терминаллары урнаштырылырга мөмкин.

18. Башкарма комитетта һәм «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесендә «Интернет» челтәренә тоташу пунктлары булдырыла.

## 5 бүлек. Мәгълүматтан файдаланучыларны китапханә һәм архив фондларындагы мәгълүмат белән таныштыру

19. Мәгълүматтан файдаланучыларны Башкарма комитет эшчәнлеге турында китапханә һәм архив фондларындагы мәгълүмат белән таныштыру Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

20. Мәгълүматтан файдаланучыларны китапханә фондында булган Башкарма комитет эшчәнлеге турындагы мәгълүмат белән таныштыру «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет

учреждениесендә (алга таба – китапханә) аның эш графигы нигезендә гамәлгә ашырыла.

21. Китапханә фондыннан һәм хезмәтләрдән файдалану хокукы барлык физик һәм юридик затларга бирелә.

22. Китапханә фондыннан файдалану тәртибе, төп хезмәтләр исемлеге һәм аларны китапханә тарафыннан күрсәтү шартлары, балаларны аларның сәламәтлегенә һәм (яки) үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан саклау турында Россия Федерациясе законнары, дәүләт сере һәм закон белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары һәм Россия Федерациясе халыкларының мәдәни байлыгы сакланышын тәэмин итү турындагы законнар нигезендә, китапханә уставы белән билгеләнә.

## 6 бүлек. Гражданнарның (физик затларның) коллегиаль органнар утырышларында катнашуы

23. Башкарма комитетның коллегиаль органнары утырышларын үткәргәндә, аларда гражданнарның (физик затларның), шул исәптән оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләренең катнашу мөмкинлеге Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә тәэмин ителә.

## 7 бүлек. Мәгълүматтан файдаланучыларның запросы буенча аларга мәгълүмат бирү

24. Язма рәвештә төзелгән һәм Башкарма комитетка кергән, шулай ук «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында күрсәтелгән электрон почта адресы аша кергән запросларны теркәүне һәм әлеге запросларга җавапларның үз вакытында җибәрелүен контрольдә тотуны Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе гамәлгә ашыра.

25. Язма рәвештә төзелгән һәм Башкарма комитетның структур бүлекчәләренә кергән, шулай ук «Интернет» челтәрендә әлеге бүлекчәнең рәсми сайтында (булган очракта) күрсәтелгән электрон почта адресы аша кергән запросларны теркәүне һәм әлеге запросларга җавапларның үз вакытында җибәрелүен контрольдә тотуны Башкарма комитетның тиешле структур бүлекчәсе гамәлгә ашыра. Запросларны карап тикшерү 8-ФЗ номерлы Федераль законда, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова